МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.11.2021 Казан ш. № 09-116

Учетны үзәкләштергәндә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бердәм учет сәясәте документларын раслау турында

Учетны үзәкләштергәндә бердәм учет сәясәтен формалаштыру максатларында һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгының ""Бухгалтерлык учетының һәм дәүләт секторы оешмалары отчетларының концептуаль нигезләре" дәүләт секторы оешмалары өчен бухгалтерлык учеты федераль стандартын раслау турында" 2016 елның 31 декабрендәге № 256н боерыгы белән расланган "Бухгалтерлык учетының һәм дәүләт секторы оешмалары отчетларының концептуаль нигезләре" дәүләт секторы оешмалары өчен бухгалтерлык учеты федераль стандартының 14 пунктына, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының ""Учет сәясәте, бәяләү кыйммәте һәм хаталар" дәүләт секторы оешмалары өчен бухгалтерлык учеты федераль стандартын раслау турында" 2017 елның 30 декабрендәге № 274н боерыгы белән расланган "Учет сәясәте, бәяләү кыйммәте һәм хаталар" дәүләт секторы оешмалары өчен бухгалтерлык учеты федераль стандартының 9 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кайбер башкарма органнары вәкаләтләрен тапшыру турында" 2021 елның 5 маендагы № 311 карарының 3 пунктына туры китереп, боерык бирәм:

1. Расларга (кушымта итеп бирeләләр):

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үзләренә карата физик затларның хезмәтенә түләү һәм башка түләүләрне хәл итү, шулай ук аларга бәйле Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне

һәм аларны күчерү буенча, бюджет учетын алып бару буенча, бюджет хисабын төзү һәм тапшыруны алып бару буенча, бюджет учеты мәгълүматлары нигезендә булдырыла торган башка мәҗбүри хисапларны кертеп, мондый хисапны тиешле дәүләт органнарына тапшыру буенча вәкаләтләр хәл итеlә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте аерым башкарма органнарының үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләре (1 нче кушымта);

Бюджет учетын үзәкләштергәндә документлар әйләнеше графигы (2 нче кушымта);

Хуҗалык тормышы фактларын документ итеп рәсмиләштерүне, үзәкләштерелүче вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар (мәгълүмат) тапшыруны (алуны) тәэмин итү буенча Министрлык һәм үзәкләштерелгән учет субъекты арасында үзара хезмәттәшлек регламенты (3 нче кушымта).

2. Бу боерык 2022 елның 1 гыйнварыннан көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны – Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Казначылык департаменты директоры М.Д. Фәйзрахмановка йөкләргә.

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
_________ 2021 ел, № _______
боерыгына № 1 кушымта

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үзләренә карата физик затларның хезмәтенә түләү һәм башка түләүләрне хәл итү, шулай ук аларга бәйле Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне һәм аларны күчерү буенча, бюджет учетын алып бару буенча, бюджет хисабын төзү һәм тапшыруны алып бару буенча, бюджет учеты мәгълүматлары нигезендә булдырыла торган башка мәҗбүри хисапларны кертеп, мондый хисапны тиешле дәүләт органнарына тапшыру буенча вәкаләтләр хәл ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте аерым башкарма органнарының үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләре

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан үзләренә карата физик затларга хезмәткә түләү һәм башка түләүләрне хәл итү, шулай ук аларга бәйле Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне һәм аларны күчерү буенча, бюджет учетын алып бару буенча, бюджет хисабын төзү һәм тапшыруны алып бару буенча, бюджет учеты мәгълүматлары нигезендә булдырыла торган башка мәҗбүри хисапларны кертеп, мондый хисапны тиешле дәүләт органнарына тапшыру буенча вәкаләтләр (ала таба – үзәкләштерелгән вәкаләтләр, Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләре) хәл ителә торган, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте аерым башкарма органнарының (алга таба – Үзәкләштерелгән учет субъектлары) үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләре учетны үзәкләштерүдә бердәм учет сәясәте кысаларында һәм “Дәүләт секторы оешмалары өчен “Дәүләт секторы оешмаларының бухгалтерия учеты һәм хисабының концептуаль нигезләре” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 31 декабрь, 2016 ел, № 256н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган дәүләт секторы оешмалары өчен “Дәүләт секторы оешмаларының бухгалтерия учеты һәм хисабының концептуаль нигезләре” бухгалтерия учеты федераль стандарты таләпләре нигезендә, үзәкләштерелгән учет субъектлары тарафыннан Үзәкләштерелгән учет субъектларының бюджет учетын алып баруны һәм бюджет хисабын булдыруны оештыру өчен кирәкле бюджет учетын алып баруның төп ысулларын, бюджет учеты объектларын бәяләү ысулларын, бюджет учеты объектларын тану тәртибен (учетка куюны) һәм тануны туктату (учеттан чыгу) тәртибен һәм (яки) алар турында мәгълүматларны бюджет хисабында ачу тәртибен, бюджет учетында тану тәртибен һәм хисап датасыннан соңгы вакыйгаларны бюджет хисабында тану тәртибен, шул исәптән учетта һәм (яки) еллык бюджет хисабында хисап датасыннан соң вакыйгалар турында мәгълүматларны ачу өчен беренчел учет документларын тапшыруның чик датасын, шулай ук бюджет учетын алып баруның башка ысулларын билгели.

Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып үзенчәлекләре түбәндәге документлар нигезендә эшләнде:

Россия Федерациясе Бюджет кодексы;

Россия Федерациясе Салым кодексы;

“Бухгалтерия учеты турында” 6 декабрь, 2011 ел, № 402-ФЗ Федераль закон;

“Дәүләт хакимияте” органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, дәүләт фәннәр академияләре, дәүләт (муниципаль) учреждениеләр өчен Бухгалтерия учеты счетларының бердәм планын һәм аны куллану буенча Инструкцияне раслау турында” 1 декабрь, 2010 ел, № 157н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы (алга таба – № 157н Инструкция);

“Бюджет учеты счетлары планын һәм аны куллану буенча Инструкцияне раслау турында” 6 декабрь, 2010 ел, № 162н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодларын формалаштыру һәм куллану тәртибе, аларның структурасы һәм билгеләнеше принциплары турында” 6 июнь, 2019 ел, № 85н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы (алга таба – № 85н Боерык);

“Дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясен куллану тәртибен раслау турында” 29 ноябрь, 2017 ел, № 209н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы (алга таба – № 209н Боерык);

“Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү турында еллык, кварталлык һәм айлык хисапларны төзү һәм тапшыру тәртибе хакындагы инструкцияне раслау турында” 28 декабрь, 2010 ел, № 191н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары, дәүләт (муниципаль учреждениеләр тарафыннан кулланыла торган беренчел учет документлары һәм бухгалтерия учеты регистрлары һәм аларны куллану буенча Методик күрсәтмәләр формаларын раслау турында” 30 март, 2015 ел, № 52н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Дәүләт секторы оешмаларының бухгалтерия учетының һәм хисабының концептуаль нигезләре” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 31 декабрь, 2016 ел, № 256н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы (алга таба – № 256н Боерык);

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Төп средстволар” бухгалтерия учетының федераль стандартын раслау турында” 31 декабрь, 2016 ел, № 257н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Аренда” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 31 декабрь, 2016 ел, № 258н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Активларның бәясе төшү” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 31 декабрь, 2016 ел, № 259н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Бухгалтерия (финанс) хисабын тапшыру” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 31 декабрь, 2016 ел, № 260н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Учет сәясәте, бәяләү күрсәткечләре һәм хаталар” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 30 декабрь, 2017 ел, № 274н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Хисап датасыннан соңгы вакыйгалар” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 30 декабрь, 2017 ел, № 275н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Акча средстволары хәрәкәте турында хисап” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 30 декабрь, 2017 ел, № 278н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы (алга таба – № 278н Боерык);

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Керемнәр” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 27 февраль, 2018 ел, № 32н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Бухгалтерия (финанс) хисабында бюджет мәгълүматлары” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 28 февраль, 2018 ел, № 37н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Чит илләр валюталары курслары үзгәрүнең йогынтысы” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 30 май, 2018 ел, № 122н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Резервлар. Шартлы йөкләмәләр һәм шартла активлар турында мәгълүматларны ачу” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 30 май, 2018 ел, № 124н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Озак сроклы килешүләр” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 29 июнь, 2018 ел, № 154н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Концессион килешүләр” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 29 июнь, 2018 ел, № 146н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Запаслар” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 7 декабрь, 2018 ел, № 256н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Җитештерелмәгән активлар” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 28 февраль, 2018 ел, № 34н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Матди булмаган активлар” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 15 ноябрь, 2019 ел, № 81н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Кредитлар буенча чыгымнар” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 15 ноябрь, 2019 ел, № 182н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Уртак эшчәнлек” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 15 ноябрь, 2019 ел, № 183н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Персоналга түләү” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 15 ноябрь, 2019 ел, № 184н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы;

“Дәүләт секторы оешмалары өчен “Финанс инструментлары” бухгалтерия учеты федераль стандартын раслау турында” 30 июнь, 2020 ел, № 129н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы.

Баланстан тыш счетларда, йөкләмәләрдә исәпкә алына торган активларга, милеккә һәм бюджет учетының башка объектларына инвентарьлаштыруны үткәрү тәртибе

Үзәкләштерелгән учет субъектлары тарафыннан билгеләнә. Министрлык хезмәткәрләренең инвентаризация комиссияләрендә катнашуы таләп ителми.

Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләре эзлекле төстә ел сае кулланыла.

Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләренә үзгәрешләр кертү Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләренең 11 бүлегендә күздә тотылган тәртиптә хәл ителә.

Бюджет учеты автомат рәвештә, "Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар карамагындагы учреждениеләрнең бухгалтерия учеты һәм хисабы дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – ГИС РТ) файдалану ысулы белән хәл ителә.

## 2. Үзәкләштерелгән бюджет учетын оештыру һәм алып бару

Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып баруда операцияләрне чагылдыру, Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләренә номер № 1 кушымта нигезендә, Үзәкләштерелгән бюджет учеты счетларының эш планы (алга таба – Счетларның эш планы) нигезендә хәл ителә.

Счетларының эш планына кертелеп, Үзәкләштерелгән учет субъектларының бюджет учетын алып бару өчен кулланыла торган бюджет учеты счетлары номерларын (бухгалтерия (бюджет) учеты – синтетик һәм аналитик учетның счетлары кодлары) булдыру, түбәндәге бюджет классификация кодларын чагылдырып, № 157н Инструкция һәм № 162н Инструкция нигезләмәләреннән чыгып хәл ителә:

кодларның 1-17 разрядларында, № 162н Инструкциядә күздә тотылган үзенчәлекләрдән чыгып, бюджетлар керемнәре, бюджетлар чыгымнары, бюджет классификациянең бюджетлар дефицитларын финанслау чыганаклары классификациясенең 4-20 разрядлары;

кодларның 18 разрядында финанс белән тәэмин итү төре: "1" – бюджет эшчәнлеге, һәм "3" – вакытлыча карамактагы средстволар;

19-21 разрядларда – Счетларның эш планының синтетик счеты коды;

22-23 разрядларда – Счетларның эш планының аналитик счеты коды;

24-26 разрядларда – Учет объектының керү, чыгуының аналитик счеты коды.

Бюджет учеты счетлары номерларына кертелгән бюджет классификациясе хаклары № 85н боерык, № 209н боерык һәм агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында закон нигезендә кулланыла.

Чыгымнарны хәл итүдә "Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль казна, бюджет һәм автоном учреждениеләре чыгымнарын планлаштыру һәм хәл итүне оештыру буенча эш регламентын раслау турында" 20.12.2016 ел, № 21-52-59 Министрлык боерыгы нигезендә өстәмә классификация кулланыла.

Министрлык тарафыннан үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару өчен – алар буенча бюджет учетын алып баруны, бюджет хисабын формалаштыруны җайга салучы норматив-хокукый актлар нигезендә – кулланыла торган бюджет учеты регистрлары, бюджет учетының башка документлары Министрлык тарафыннан, бюджет учетын алып баруны, бюджет хисабын формалаштыруны җайга салучы норматив-хокукый актлар таләпләре игезендә билгеләнә.

Чит телдә төзелгән беренчел учет документларының Үзәкләштерелгән учет субъекты боерыгы нигезендә билгеләнгән Үзәкләштерелгән учет субъекты хезмәткәре тарафыннан яки Үзәкләштерелгән учет субъекты килешү нигезендә җәлеп иткән башка

белгеч тарафыннан яки документны тапшырган зат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә (тәрҗемәнең дөреслеге өчен җавап бирә) рус теленә тәрҗемәсе булырга тиеш.

Министрлык Үзәкләштерелгән учет субъектлары тарафыннан үзәкләштерелгән вәкаләтләрне хәл кылуда беренчел электрон документларның түбәндәге унификацияләнмәгән формаларын куллана:

Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләренә № 2 кушымтасы нигезендәге форма буенча бюджетларга акча керемнәре турында реестр ;

Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләренә № 3 кушымтасы нигезендәге форма буенча, бюджетлар керемнәре турында бурыч суммалары реестры;

Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләренә № 4 кушымтасы нигезендәге форма буенча, түләтеп булмый торган гамәлдән алынган бурыч суммалары реестры.

Бюджет учеты регистрларын формалаштыру электрон документ (регистр рәвешендә) ай саен, бюджет учеты регистрларын тәгаенләштерү нигезендә, квалификацияле электрон имзадан файдаланып хәл ителә:

“Касса” счеты буенча операцияләр журналы;

“Тере” акча средстволары белән операцияләр журналы;

хисап бирергә тиешле затлар белән исәп-хисаплар операцияләре журналы;

тәэмин итүчеләр һәм подрядчылар белән исәп-хисаплар операцияләре журналы;

керемнәр буенча дебиторлар белән исәп-хисаплар операцияләре журналы;

хезмәткә түләү һәм стипендияләр буенча исәп-хисаплар операцияләре журналы;

узган еллардагы хаталарны төзәтү буенча операцияләр журналы.

хисап арасындагы чор операцияләре журналы;

финанс булмаган активлар чыгу һәм күчү буенча операцияләр журналы;

башка операцияләр буенча журнал (алга таба – Операцияләр журналы).

Һәр үзәкләштерелгән учет субъекты буенча аерым төп кенәгә булдырыла.

Электрон документ рәвешендә керем һәм чыгым касса ордерларын теркәү журналын булдыру (форма 0504093) һәр ел саен (хисап финанс елы тәмамлангач) хәл ителә һәм, кирәк булганда, Министрлыкның вәкаләтле заты тарафыннан квалификацияле электрон имза белән имзалана.

Үзәкләштерелгән учет субъекты 01 (федераль бюджет” һәм 02 “Россия Федерациясе субъекты бюджеты” бюджет элементыннан аермалы элемент коды белән бүленә торган керемнәр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре администраторының бюджет вәкаләтләрен хәл иткән очракта, Төп кенәгәне булдыру (форма 0504072) Россия Федерациясе бюджет системасының һәр коды буенча хәл ителә.

Бюджет учеты регистрлары, электрон документлар рәвешендә булдырылган бюджет учетының башка документлары күчермәләрен кәгазьдә булдыру (электрон документларның үрнәкләрен кәгазьдә булдыру) аларны электрон документлар рәвешендә саклау мөмкинлеге булмаганда һәм мондый документларны һәр хисап чоры (ай, квартал, ел) узгач һәм хисап тапшырганнан соң кәгазьдә саклауны тәэмин итәргә кирәк булган очракта хәл ителә.

Тәэмин итүче (подрядчы, эш башкаручы) тапшырган беренчел учет документлары, хисап чорының соңгы эш көнендә тапшырылган, әмма Үзәкләштерелгән учет субъектыннан хисап аеннан соң килүче айда алынган документлар:

хисап тапшыру датасына биш һәм аннан күбрәк эш көне калганда – алдагы ай белән чагылдырыла;

хисап тапшыру датасына кимендә биш эш көне калганда – алар алынган айда чагылдырыла.

Тәэмин итүче (подрядчы, эш башкаручы) тарафыннан хисап елының соңгы эш көнендә тапшырылган, әмма Үзәкләштерелгән учет субъектына хисап чорыннан соң килүче елда алынган беренчел учет документлары:

хисап тапшыру датасына 10 һәм аннан күбрәк эш көне калганда – алдагы ай белән чагылдырыла;

хисап тапшыру датасына 10 эш көненнән кимрәк калганда – аларның алыну аенда чагылдырыла.

Министрлык тапшырылган (булдырылган) беренчел учет документларын, бюджет учетының башка документларын дәүләт архивы эшен оештыру кагыйдәләре нигезендә саклауны тәэмин итә.

Үзәкләштерелгән учет субъекты җитәкчесе һәм (яки) Министрлыкның вәкаләтле заты алышынганда, бюджет учеты документларын Үзәкләштерелгән учет субъектына тапшыру көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салынган бюджет учеты күрсәткечләрен кабул итү-тапшыру акты буенча электрон рәвештә хәл ителә.

## 3. Финанс булмаган активлар учеты

Бюджет учетында билгесез срокка төелгән аренда килешүе буенча операцион аренда учетын чагылдыру максатында, бюджет циклының өч еллык чорын һәм аренда килешүендә күрсәтелгән аренда түләүләре күләмен исәпкә алып, Үзәкләштерелгән учет субъектының өзлексез эшчәнлеген тәэмин итү принцибына таянырга кирәк.

Милек объектының бер өлешен файдалануга тапшыру очрагында, тапшырыла торган өлешнең бәясе аның мәйданына пропорциональ рәвештә исәпләнелә һәм үзәкләштерелгән бюджет учеты счетларының эш планында расланган тиешле баланстан тыш счетларда чагылдырыла.

### 3.1. Төп средстволар объектлары учеты

#### 3.1.1. Төп средстволар объектының инвентарь номерының код билгеләнешләре структурасы

Үзәкләштерелгән учет субъектына үзәкләштерелгән вәкаләтләр тапшырылганчы бюджет учетына кабул ителгән төп средстволар объектының инвентарь номеры мәгълүматлар базасы тапшырылганнан соң үзгәртелми.

Бюджет учетына кабул ителгәндә төп средстволарның һәр инвентарь объектына (объектлар төркеменә) министрлык инвентарь тәртип номерын (алга таба – төп средстволар объектының инвентарь номеры) бирә. Төп средстволар объектының (объектлар төркеменең) инвентарь номеры 17 билгедән тора, алар төп средстволар объектын учетка алуга карап, эзлекле төстә билгеләнелә:

1-3 разрядлар – Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүче кодына туры килүче Үзәкләштерелгән учет субъекты коды;

4-6 разрядлар – счетларның эш планында синтетик счет объекты коды;

7-8 разрядлар – счетларның эш планында синтетик счет төркеме һәм төре коды;

9-17 разрядлар – инвентарь объектының тәртип номеры.

3.1.2. Төп средстволарның инвентарь объектларын учетка алуга кабул итү

Төп средстволар объектларын учетка алуны кабул итү (төп средстволар объектларын учеттан төшерү) Министрлык тарафыннан Үзәкләштерелгән учет субъекты активлары керү һәм чыгу буенча Комиссия карары нигезендә хәл ителә.

Төп средстволарны активлар яки активлар булмаган категорияләргә кертү турында календарь елы эчендә шулай ук төп средстволар объектларының максатчан функцияләре үзгәрү очрагында еллык бюджет (финанс) хисабы күрсәткечләрен раслау максатындагы Комиссия карарлары Министрлык тарафыннан раслаган Бюджет учетын үзәкләштерүдә документлар әйләнеше графигы игезендә учетта чагылдыруга кабул ителә.

Төп средстволарны дәүләт контрактлары (килешүләр) шартлары нигезендә документларда расланган факт буенча учетка алу Үзәкләштерелгән учет субъекты активлары составына төп средстволар объектын кабул итү турында Комиссия карары нигезендә хәл ителә. Шул ук вакытта Финанс булмаган активлар объектларын кабул итү-тапшыру турында акт (форма 0504101) формалаштыру таләп ителми. Матди кыйммәтләрне (финанс булмаган активларны) кабул итүгә керем ордеры (форма 0504207) беренчел учет документларында объектны тапшырган һәм кабул иткән җаваплы затлар күрсәтелмәгән очракларда рәсмиләштерелә.

Тәэмин итүче документларында төп средстволар объектының состав өлешләре бәясе турында мәгълүматлар булганда, мондый мәгълүмат Финанс булмаган активлар учетының инвентарь карточкасында чагылдырыла (форма 0504031).

Төп средстволар объектларын сатып алуга, шулай ук китереп кую хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бәясе төп средстволар объектлары төрләре бәясенә пропорциональ рәвештә бүлүне.

Төп средстволар объектларының гадел бәясе азар бәясе ысулы белән билгеләнә.

Бушлай алынган финанс булмаган активларның бәясе активларның һәм йөкләмәләрнең төрле төрләренең гадел бәясе буенча билгеләнә. Шул ук вакытта түбәндәге документлардагы мәгълүматлар нигезендә базар бәяләре кулланырга кирәк.

дәүләт статистика органнары белешмәләрендә һәм башка документларда;

җитештерүче оешмаларның прайс-кәгазьләрендә;

эксперт бәяләмәләрендә;

массакүләм мәгълүмат чараларында.

Төп средстволар булып торучы, бәясе 10000,00 сумга кадәрге күчемсез милек объектларын файдалануга тапшыру, китапханә фонды объектларыннан тыш, Учреждение ихтыяҗларына матди кыйммәтләр тапшыру ведомосте (форма 0504210) нигезендә рәсмиләштерелә. Ведомостьне Үзәкләштерелгән учет субъектының вәкаләтле затлары раслый, һәм ул 10000,00 сумга кадәрге бәядәге төп средстволар объектларын баланс учетыннан алуга, баланстан тыш учет счетларында файдалануга кертелгән объектны баланс бәясен чагылдырып, нигез булып хезмәт итә.

Активлар керү һәм чыгу буенча комиссия (алга таба – Комиссия) тарафыннан алга таба файдалану, ремонтлау, торгызу нәтиҗәсез дип билгеләнгән Үзәкләштерелгән учет субъектының төп средстволары объектлары, әлеге мөлкәтнең 1 объект 1 сум шартлы бәяләмәсендә функциональ билгеләнешен алга таба билгеләгәнче (хуҗалык әйләнешенә

кертү, сату яки гамәлдән алу), “саклауга кабул ителгән матди кыйммәтләр” 02 баланстан тыш счетта чагылдырылырга тиеш.

Төп средстволар бердәм инвентарь объектка (төп средстволар объектлары комплексына) берләштерелгәндә, төп средстволар, финанс булмаган активларны (транспорт чараларыннан тыш) гамәлдән чыгару турында акт рәсмиләштереп (форма 0504104), комиссия карары нигезендә, алдан исәпләнгән аммортизация һәм бәя төшүдән китерелгән зыян (булганда) белән, учеттан төшеп кала. Төп средстволарның бердәм объекты Финанс булмаган активлар объектларын кабул итү-тапшыру турында рәмиләштерелгән ак (форма 0504101) нигезендә, Комиссия карары буенча учетка кабул ителә. Гамәлдән алынган аммортизация һәм бәя төшүдән китерелгән зыян (алар берләштерелә торган төп средстволар буенча гамәлдән алынса), бухгалтерия белешмәсе (форма 0504833) нигезендә, берләштерелгән төп средство буенча исәпләнгән аммортизация һәм китерелгән зыян сыйфатында учетка кабул ителә.

Төп средстволар объектыннан (аның составы өлешләреннән) файдалану тәртибе объектның аерым состав өлешләрен алыштыруны таләп иткән очракта мондый алыштыру чыгымнары, шул исәптән капиталь ремонт барышындагы чыгымнар, алар килер чыгуга ук төп средстволар объекты бәясенә кертелә.

Төп средстволар объекты бәясен алыштырыла торган (чыгарыла торган) өлешләр бәясе киму алыштырыла торган өлешләр бәясе билгеле булганда гына мөмкин. Алыштырыла торган объект бәясен ышанычлы төстә билгеләү мөмкин булмаганда, шулай ук мондый алыштыру нәтиҗәшсендә актив критерийләрен канәгатьләндерердәй мөстәкыйль объект булдырылмаганда, ремонтланыла торган объект бәясе киметелми.

Бюджет учетында төп средстволар объектының башлангыч бәясен үзгәртү турында нигезләмәләрне куллану түбәндәге төп средстволар төркемнәренә карата алыштыру (өлешчә алыштыру) очракларында хәл ителә:

торак булмаган бүлмәләр (биналар һәм корылмалар);

машиналар һәм җиһазлар;

транспорт чаралары;

производство һәм хуҗалык кирәк-яраклары.

3.2. Матди булмаган активлар объектлары учеты

3.2.1. Матди булмаган активлар объектының инвентарь номерының код билгеләнешләре структурасы

Бюджет учетына кабул итү вакытында матди булмаган активларның һәр инвентарь объектына (объектлар төркеменә) инвентарь тәртип номеры (алга таба – матди булмаган активлар объектының инвентарь номеры) бирелә. Матди булмаган активлар объектының инвентарь номеры унҗиде билгедән тора, алар матди булмаган активларны учетка кабул итүгә карап, эзлекле төстә билгеләнелә.

1-3 разрядлар буенча – Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүче кодына туры килүче Үзәкләштерелгән учет субъекты кодь;

4-6 разрядлар буенча– счетларның эш планында синтетик счет объекты коды;

7-8 разрядлар буенча– счетларның эш планында синтетик счет төркеме һәм төре коды;

9-17 разрядлар буенча – инвентарь объектының тәртип номеры.

3.2.2. Матди булмаган активларның инвентарь объектларын (инвентарь объектлар төркемнәрен) учетка алуга кабул итү

Матди булмаган активлар объектларын учетка кабул итү (матди булмаган активлар учетыннан чыгару) Министрлык тарафыннан, матди булмаган активның бәясен һәм аның файдалану срогын күрсәтеп, Комиссия карары нигезендә хәл ителә.

Матди булмаган активларны активлар яки активлар булмаган категорияләргә кертү турында календарь елы эчендә, шулай ук матди булмаган активлар объектларының максатчан функцияләре үзгәрү очрагында еллык бюджет (финанс) хисабы күрсәткечләрен раслау максатындагы Комиссия карарлары Министрлык тарафыннан раслаган Бюджет учетын үзәкләштерүдә документлар әйләнеше графигы нигезендә учетта чагылдыруга кабул ителә.

Матди булмаган активларны дәүләт контрактлары (килешүләр) шартлары нигезендә документларда расланган факт буенча учетка алу Матди булмаган активлар объектын кабул итү турында Комиссия карары нигезендә хәл ителә. Шул ук вакытта Финанс булмаган активлар объектларын кабул итү-тапшыру турында акт (форма 0504101) формалаштыру таләп ителми. Матди кыйммәтләрне (финанс булмаган активларны) кабул итүгә керем ордеры (форма 0504207) беренчел учет документларында объектны тапшырган һәм кабул иткән җаваплы затлар күрсәтелмәгән очракларда рәсмиләштерелә.

Матди булмаган объектны бюджет учетына кабул итү датасы булып, Россия Федерациясе законы нигезендә, әлеге объектка Үзәкләштерелгән учет субъекты йөзендә Россия Федерациясе тулы хокукы килеп чыгу вакыты танылa.

Матди булмаган активларны модернизацияләү нәтиҗәләре Комиссия карары һәм тиешле матди булмаган активлар объектында хәл ителгән капиталь салуларны раслаган документларның керү факты буенча матди булмаган активлар бәясен кыйммәтләндерү максатында учетка кабул ителә.

3.2.3. Матди булмаган активлар һәм интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләреннән файдалану хокуклары учеты

Интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә һәм аларга тигезләштерелгән индивидуализация средстволарына тулы хокуклар “Матди булмаган активлар: 0 102 00 000 счетларының аналитик учеты тиешле счетларында чагылдырылырга тиеш:

0 102 0N 000 «Фәнни тикшеренүләр (фәнни-тикшеренү эшләнмәләре)»;

0 102 0R 000 «Тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләнмәләр»;

0 102 0I 000 «Программалар һәм мәгълүматлар базалары»;

0 102 0D 000 «Башка интеллектуаль милек объектлары».

Интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә файдалануга тулы булмаган хокуклар (интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукның булуын раслаган лицензия килешүләре яки башка документлар нигезендә, интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә

файдалану хокуклары) 0 111 60 000 «Матди булмаган активлардан файдалану хокуклары» счетының аналитик учеты тиешле счетларында чагылдырыла:

0 111 6N 000 «Фәнни тикшеренүләрдән (Фәнни тикшеренү эшләнмәләреннән файдалану хокукы)»;

0 111 6R 000 «Тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләнмәләрдән файдалану хокуклары»;

0 111 6I 000 «Программалардан һәм мәгълүматлар базаларыннан файдалану хокуклары»;

0 111 6D 000 «Башка интеллектуаль милек объектларыннан файдалану хокуклары».

Хезмәт итү срогы 12 айдан артыграк булган (12 ай плюс бер көн һәм аннан күбрәк) матди булмаган активлардан файдалануга тулы булмаган хокуклар 0 111 60 “Матди булмаган активлардан файдалану хокуклары” счетында исәпкә алына.

0 106 00 000 “Финанс булмаган активларга салулар” (матди булмаган активларга салуларны, матди булмаган активлардан файдалану хокукларын учетка алу ягыннан), 0 104 00 000 (матди булмаган активлар аммортизациясен, матди булмаган активлардан файдалану хокукларын учетка алу ягыннан) счетларында учетка алынырга тиешле операцияләр төркемнең тиешле аналитик кодларындагы һәм синтетик счет төренең тиешле кодларындагы счетлар номерлары буенча чагылдырыла:

0 106 0N 000 «Фәнни тикшеренүләр (фәнни-тикшеренү эшләнәмләре)»;

0 106 0R 000 «Тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләнмәләр»;

0 106 0I 000 «Программалар һәм мәгълүматлар базалары»;

0 1026 0D 000 «Башка интеллектуаль милек объектлары».

Үзәкләштерелгән учет субъекты (лицензиар) тарафыннан интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә яки индивидуализация средстволарына тулы хокукларны саклап калу шартларында файдалануга бирелә торган матди булмаган активлар, Счетларның эш планының 25 “Бушлай файдалануга (арендага) тапшырыла торган милек” баланстан тыш счетында бирүк вакытында чагылдырып, учет объектын эчке күчерү (баланс учетыннан чыгармыйча) юлы белән бухгалтерия язуларында чагылдырыла.

3.3. Амортизацияне исәпләүдә кулланыла торган ысуллар

Төп средстволар объектлары, матди булмаган активлар, активлардан файдалану хокуклары буенча амортизацияне исәпләү агымдагы айның соңгы календарь көне белән линия ысулы буенча хәл ителә.

Төп средстволар объекты комплексының структур өлешенә амортизация, объект бер инвентарь номерга ия булуга карамастан, төп средстволар объекты структур өлешләре белән бергә (төп средстволарның бердәм объекты) бердәм милек объектын тәшкил итүче башка өлешләренең амортизациясеннән аерым исәпләнелә.

Төп средстволар объектының структур өлешен файдалы куллану срогы төп средстволар объектының структур өлешләре белән бергә бердәм милек объектын (төп средстволарның бердәм объекты) тәшкил итүче башка өлешләрен файдалы куллану

срогына туры килсә, мондый частьләрне амортизацияләү суммасын билгеләгәндә, алар берләштерелә.

Төп средстволар объектын (шул исәптән дәүләт секторы оешмалары файдасына булмаган рәвештә алынучы төп средстволар объектларын) яңадан бәяләү датасына исәпләнгән тупланма амортизация суммасы тупланма амортизацияне яңадан исәпләү ысулы белән исәпкә алына, шул ук вакытта яңадан исәпләү датасына исәпләнгән җыелма амортизация төп средстволар объектының башлангыч бәясен пропорциональ үзгәртүдән чыгып шул рәвешле исәпләнелә: аның калдык бәясе яңадан бәяләүдән соң яңадан бәяләнгән хакка тигез булырлык итеп. Әлеге ысул баланс бәясен һәм тупланма амортизацияне бер үк коэффициентка шул рәвешле арттыру (киметүне) күздә тота: аларны кушканда яңадан бәяләүне үткәрү көненә яңадан бәяләнгән хакны алырлык итеп.

3.4. Матди запаслар учеты

Матди запаслар составында учреждение эшчәнлегендә, бәяләренә бәйсез рәвештә, 12 айдан артмаган чор эчендә файдаланыла торган объектлар исәпкә алына.

Үзәкләштерелгән учет субъекты эшчәнлегендә 12 айдан артмаган чор эчендә файдаланыла торган производство һәм хуҗалык кирәк-ярагы исемлеге Үзәкләштерелгән бюджет учеты алып бару үзенчәлекләренә № 5 кушымтада китерелгән.

Катгый хисап бланклары, Үзәкләштерелгән учет субъекты эшчәнлеге процессында файдалану өчен сатып алынган, булдырылган һәм саклау урыннарында саклана торган кыйммәтле бүләкләр, сувенир продукциясе  0 105 36 349 “Бер тапкыр кулланыла торган башка матди запаслар бәясе арту” счетында бюджет учетында чагылдырылырга тиеш.

Учет бланкларын саклауга һәм бирүгә җаваплы затка саклауга тапшырылган катгый хисап бланклары учеты 03 “Катгый хисап бланклары” баланстан тыш счетта шартлы бәядә 1 объект – 1 сум рәвешендә хәл ителә, аларның бәясе кире кайтарылмый һәм сатып алу бәясе кире кайтарылмый.

Матди запасларны үзәкләштерелгән рәвештә сатып алуга һәм (яки) сәүдә (производство) эшчәнлеген хәл кылу кысаларында, матди запасларны әзерләү һәм үзәкләштерелгән (производство) складларына (базалар) һәм (яки) йөк кабул итүчеләргә китереп бирү буенча хәл ителгән чыгымнар, матди запасларны китереп бирүне иминиятләштерүне кертеп, сатып алына торган матди запасларның факттагы бәясенә кертелми, ә агымдагы финанс елының финанс нәтиҗәсенә чыгымнар составына кертелә.

Бюджет учетында матди запаслар, Россия Госстандарт 26 декабрь, 1994 ел, № 366 карары белән расланган Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы ОК 015-94 (МК 002-97) нигезендә, номенклатур берәмлек (данә, тонна, килограмм, литр, метр, пачка һәм башкалар) буенча исәпкә алына.

Матди запасларның аналитик учеты матди запаслар төрләре буенча, кирәк булганда, саклау урыннары буенча, матди яктан җаваплы зат тарафыннан алып барыла.

Акчага сатып алынган матди запасларны бәяләү, аларны сатып алуга бәяле чыгымнардан чыгып, сатып алуның факттагы бәясе буенча хәл ителә.

Матди запасларның берничә төрен бер үк вакытта сатып алганда, мондый чыгымнар сатып алына торган материалларның килешүдәге бәясенә пропорциональ рәвештә бүленә.

Йомшак инвентарьне гамәлдән чыгару сәбәпле, финанс булмаган матди активларны, шул исәптән тузган әйберләрне, юкка чыгаруда алынган материалларны учетта тану, базар бәяләре ысулы нигезендә билгеләнелә торган, гадел бәя буенча чагылдырыла.

Базар бәясе турында мәгълүматлар расланылырга тиеш:
дәүләт статистика органнары белешмәләре һәм башка раслау документлары;
җитештерүче оешмаларның прайз-кәгазьләре;
эксперт бәяләмәләре;
массакүлләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган мәгълүмат нигезендә.

Матди запаслар чыкканда, аларны бәяләү факттагы уртача бәясеннән чыгып хәл ителә.

Ягулык-майлау материаллары (алга таба – ГСМ) чыгымы нормалары Үзәкләштерелгән учет субъектының аерым күрсәтмәсе (боерыгы) рәвешендә, "Автомобиль транспортында ягулык һәм майлау матери аллары чыгымы нормалары" методик рекодацияләрне гамәлгә кертү турында 14 март, 2008 ел, № АМ-23-р Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы боерыгы белән расланган методик рекомендацияләр (алга таба – Методик рекомендацияләр № АМ-23-р) нигезендә раслана. Автомобиль маркасы Методик рекомендацияләрдә № АМ-23-р исемләп күрсәтелмәсә, ГСМ чыгымы нормасы Үзәкләштерелгән учет субъекты тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, Үзәкләштерелән учет субъекты комиссиясе тарафыннан ягулык чыгымын контроль үлчәү актында теркәлгән контроль үлчәүләр (сынваулар) нигезендә эшләнә.

Матди запасларны (тосол, майлау материаллары, антифриз, мотор һәм трансмиссия майлары һәм башка шундый материаллар) гамәлдән алу, Методик рекомендацияләр № АМ-23-р нигезендә, Үзәкләштерелгән учет субъекты тарафыннан хәл ителә һәм Матди запасларны гамәлдән алу акты белән рәсмиләштерелә (форма 0504230).

Махсус сыекчыаларны алыштыруга бәйле автомототранспортка ремонт эшләре башкарганда, гамәлдән алу кимчелек ведомосте нигезендә хәл ителә һәм Матди запасларны гамәлдән алу акты белән рәсмиләштерелә (форма 0504230).

Көймә моторларына ГСМны гамәлдән алу, көймә моторлары һәм судно дизельләре эшен учетка алу журналлары нигезендә, Үзәкләштерелгән учет субъектының җаваплы затлары тарафыннан булдырыла торган хисаплар нигезендә хәл ителә һәм Матди запасларны гамәлдән алу акты белән рәсмиләштерелә (форма 0504230).

Кышкы өстәмәне ГСМ чыгымы нормаларына карата куллану үзәкләштерелгән учет субъекты күрсәтмәсе (боерыгы) белән билгеләнә.

Финанс булмаган активлар объектларын эшләү (булдыру), ремонт эшләрен башкару өчен подрядчы килешүе буенча матди запасларны тапшыру, матди запасны эчке күчерүне чагылдырып, баланс учетыннан тапшырыла торган объектларны гамәлдән алмыйча, накладной, кабул итү – тапшыру акты һәм ведомосте нигезендә чагылдырыла. Матди запаслар баланс счетыннан башкарылган эшләр акты яки материаллар чыгымы турында подрядчы хисабы нигезендә гамәлдән алына.

Хуҗалык ихтыяҗларына материаллар (көнкүреш химиясе, канцелярия товарлары, бер тапкыр кулланыла торган хуҗалык кирәк-яраклары) Учреждение ихтыяҗларына матди кыйммәтләр бирү ведомосте (форма 0504210) белән рәсмиләштерелә, ул матди кыйммәтләрне гамәлдән алуга нигез булып тора.

Хезмәткәрләргә вазыйфаи бурычларын үтәү өчен даими шәхсән файдалануга бирелгән, алынган милекне файдалануны күздә тотучы, шул исәптән Үзәкләштерелгән учет субъекты территориясеннән читтә, эш вакытының гамәлдәге режимы вакытыннан тыш та, форма кием-салымы һәм махсус кием-салым, аяк киеме, матди кыйммәтләр һәм башка мөлкәт, хезмәткәрләргә үзләренең вазыйфаи бурычларын үтәү өчен сатып алу вакытыннан шәхсән файдалануга тапшыру вакытына кадәр, милек составында исәпкә алына.

Шәхси файдалануга тапшырыла торган форма кием-салымын һәм махсус кием-салымны, аяк киемен гамәлдән алу Учреждение ихтыяҗларына матди кыйммәтләр бирү ведомосте (форма 0504210) нигезендә рәсмиләштерелә.

Йомшак инвентарьны (юрганнар, мендәрләр, җәймәләр һ.б.) гамәлдән алу, тузган әйберләрне кабул итү актының кире ягын тутырып, Йомшак һәм хуҗалык кирәк-ярагын гамәлдән алу акты (форма 0504143) нигезендә хәл ителә.

Хезмәткәрләргә шәхси файдалануга тапшырылган матди запаслар баланс учетыннан гамәлдән алына һәм 27 “Хезмәткәрләргә шәхси файдалануга тапшырылган матди кыйммәтләр” баланстан тыш учетында исәпкә алына. Хезмәткәрләрнең шәхси файдалануыннан чыгарылган, алга таба файдалану өчен яраклы матди запасларның складка алынуы учетта 27 счет күрсәткечен киметү юлы белән һәм 0 105 00 000 “Матди запаслар” счеты дебеты корреспонденциясе һәм 0 401 10 172 “Активлар белән операцияләр керемнәре” кредиты буенча чагылдырыла.

Хезмәткәрләргә ярдәм күрсәтү өчен, шулай ук аптечкаларны тулыландыру өчен медикаментларны гамәлдән алу Матди запасларны гамәлдән алу акты (форма 0504230) белән рәсмиләштерелә.

Шәхси файдалануга тапшырылган башка милекне гамәлдән алу Үзәкләштерелгән бюджет учетын алып бару үзенчәлекләренә № 6 кушымта нигезендәге форма буенча, Финанс булмаган активлар объектларының кимчелек ведомосте нигезендә хәл ителә.

3.5. Җитештерелмәгән активлар объектының инвентарь номерының код билгеләнешләре структурасы

Бюджет учетына кабул итү вакытына җитештерелмәгән активларның һәр инвентарь объектына инвентарь тәртип номеры (алга таба – җитештерелмәгән активлар объектының инвентарь номеры) бирелә. Җитештерелмәгән активлар объектының инвентарь номеры 17 билгедән тора, алар җитештерелмәгән активлар учетына кабул итүгә карап, эзлекле төстә билгеләнә:

1-3 разрядлар буенча – Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүче кодына туры килүче Үзәкләштерелгән учет субъекты коды;

4-6 разрядлар буенча – счетларның эш планында синтетик счет объекты коды;

7-8 разрядлар буенча – счетларның эш планында синтетик счет төркеме һәм төре коды;

9-17 разрядлар буенча – инвентарь объектының тәртип номеры.

4. Татарстан Республикасы бюджетында җыела торган керемнәр буенча исәп-хисапларның аналитик учеты

Акча керемнәре буенча исәп-хисапларның аналитик учеты түләүчеләр, документлар буенча керемнәр (акча керемнәре) төрләре буенча – нигезләр буенча алып барыла, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен хәл итү тәртибен билгеләүче норматив-хокукый актларда башкача күздә тотылмаганда, керем суммасын һәм аларга туры килүче суммаларны исәпләү өчен Средстволар һәм исәп-хисаплар учеты карточкасында (форма

0504051) һәм Керемнәр буенча дебеторлар белән исәп-хисаплар операцияләр журналында (форма 0504071) исәпләү өчен нигезләр буенча.

Үзәкләштерелгән учет субъекты тарафыннан шикле бурычка ия булган түләүгә сәләтсез дебеторлар бурычын, шул исәптән, шикле бурычның актив буларак тану критерийләре шартларында, яисә Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә тану шартларында, дебеторлык бурычын түләтеп булмый (өметсез) дип тану очрагында, бер үк вакытта дебеторлар бурычы учеты буенча түбәнлдәге операцияләр хәл ителә. Шикле бурыч сумасы баланс счетыннан алына һәм 04 (шикле бурыч) балланстан тыш счетта чагылдырыла.

Шикле бурычны "04 "Шикле бурыч" баланстан тыш счеттан алу Комиссия карары нигезендә хәл ителә:

күзәтү срогы чыккач (биш ел) Россия Федерациясе законында башкача күздә тотылмаганда);

шикле бурычны түләтү процедурасы яңартылганда (шикле бурычны баланс учетында яңарту очрагында);

средстволар шикле бурычны түләүгә кабул итеп алынганда.

Комиссия түләү срогы чыккан дебеторлык бурычы буенча документларны тикшерү нәтиҗәләре буенча карар чыгара һәм аны язмача рәвештә Үзәкләштерелгән учет субъекты җитәкчесенә яки башка вәкаләтле затка раслауга тапшыра.

Түләү срогы чыккан (өметсез) дебеторлык бурычын баланс (баланстан тыш) учетыннан алу Үзәкләштерелгән учет субъектының бюджетлар керемнәре администраторы вәкаләтләре нигезендә кабул ителгән боерыгына туры китереп хәл ителә.

5. Хисап тотарга тиешле затлар белән исәп-хисаплар

Хисап тотарга тиешле затлар белән исәп-хисапларны түбәндәге үзенчәлекләрдән чыгып алып барырга кирәк:

матди яктан җаваплы затларга хисап бирелергә тиешле суммаларны хуҗалык чыгымнарына 10000,00 сум күләмендә, күп дигәндә 10 көнлек вакытка, почта корреспонденциясен җибәрүгә – бер айга кадәр вакытка;

хисап бирелергә тиешле рәвештә командировка чыгымнарына алынган акча средстволары буенча хисапны командировка тәмамланганнан соң өч эш көне эчендә тапшыру;

хезмәт урынындагы коррепонденция җибәрүнең өзлексезлеген тәэмин итү максатыннан, хисап бирелергә тиешле элек тапшырылган почта маркалары һәм маркалары калдыгы булганда, почта маркаларын һәм конвертларын тапшыруны.

6. Дебиторлар һәм кредиторлар белән исәп-хисаплар

Дебиторлор һәм кредиторлар белән исәп-хисаплар учеты түләүгә тапшырылган счетлар, накладнойлар, башкарылган эшләр актлары һәм башка беренчел учет документлары нигезендә алып барыла.

Матди кыйммәтләр җитмәүдән (урлаудан) зыян күләме Үзәкләштерелгән учет субъекты комиссиясе тарафыннан билгеләнелә торган бәяләү хакыннан чыгып билгеләнә.

Вакытында башкарылмаган һәм тану критерийләренә туры килмәгән дебеторлык бурычы активы буенча резерв булдырыла.

Резерв күләме Комиссия тарафыннан, бурычлының финанс торышына (түләү сәләтенә) һәм бурычны тулысынча яки өлешчә түләү мөмкинлеген бәяләүгә бәйле рәвештә һәр шикле бурыч буенча аерым билгеләнә.

Шикле бурыч буенча резерв елына ким дигәндә бер тапкыр булдырыла (үзгәртелә).

Шикле бурыч буенча резерв суммасы (резервны үзгәртү) 0 401 10 173 "Агымдагы финанс елы керемнәре" счетына керетелә.

7. Йөкләмәләр учеты

7.1 Хезмәт хакы буенча һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләр учеты

Физик затларга хезмәткә түләү һәм башка түләүләр буенча түләүләрне исәпләүне чагылдыру, шул исәптән физик затлар белән килешүләр (контрактлар) нигезендә хәл ителә торган түләүләрне чагылдыру, шулай ук исәпләнгән суммалардан тотып калуларны чагылдыру Расчет ведомостеннән (форма 0504402) файдалану нигезендә хәл ителә.

Физик затларга хезмәткә түләү буенча түләүләрне һәм башка түләүләрне исәпләүләрне, шулай ук аларга бәйле Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләрне бюджет учеты счетларында чагылдыру һәм аларны күчерү төркем ысулы белән хәл ителә.

7.2 Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча йөкләмәләр учеты

Бюджет учетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетында мәҗбүри түләүләр буенча йөкләмәләрне тану түбәндәгечә хәл ителә:

салымнар, җыемнар, иминиятләштерү взнослары ягыннан – исәпләү хәл ителә торган айның соңгы көненә салым декларацияләре (исәп-хисаплар нигезендә);

дәүләт пошлиналары ягыннан – юридик затлар тарафыннан дәүләт пошлинасы түләнергә тиешле гамәлләр кылуны раслаган документлар (дәүләт (муниципаль) хезмәтләр алуны раслаган документлар) нигезендә;

физик затлар керемнәренә салым ягыннан – бер үк вакытта хезмәт хакы түләү һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләрне танып, Расчет ведомосте (форма 0504402) нигезендә.

7.3. Кичектерелгән йөкләмәләрне (алдагы чыгымнар резервларын) формалаштыру тәртибе

Чыгымнарны күләме һәм (яки) үтәү вакыты буенча билгеләнмәгән йөкләмәләр буенча учреждениенең финанс нәтиҗәсенә тигез кертү максатыннан чыгып, түбәндәге резервлар төрләре формалаштырыла:

фактта эшләгән вакыт өчен чираттагы ялларга алга таба түләүгә яки файдаланылмаган чираттагы ялга компенсацияләргә, шул исәптән эштән җибәрелгәндә, мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенә иминиятләштерү взносларын түләүне, вакытлыча эшкә яраксызлык очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләштерүне, мәҗбүри медицина иминиятләштерүен, производствода бәхетсезлек очракларыннан һәм хезмәткәрнең профессиональ авыруларыннан мәҗбүри социаль иминиятләштерүен кертеп, чираттагы яллар резервы;

дәгъва таләпләре һәм дәгъвалар буенча, шул исәптән суд тәртибендә бәхәсле дип игълан ителгәннәре буенча, резерв;

хуҗалык эшчәнлеге (алыш-бирешләр, операцияләр) фактлары буенча, аларны исәпләү буенча хисап датасына, беренчел учет документлары булмау сәбәпле, аларның күләме ягыннан билгесезлек булганда, килеп чыгучы йөкләмәләр буенча резервлар.

Резервларны формалаштыру (кичектерелгән йөкләмәләр счетында чагылдыру) Бухгалтерия белешмәсен (форма 0504833) нигезендә бәяләү күрсәткечләренә туры китереп хәл ителә.

Чираттагы яллар резервы рәвешендә бәяләү йөкләмәсе һәр ел саен, хезмәткәрнең күрсәтелгән датага файдаланылмыйча калган чираттагы ялы көннәре саны турында мәгълүматтан чыгып, елның соңгы көненә билгеләнә.

Чираттагы яллар резервы, һәр хезмәткәр буенча, уртача хезмәт хакыннан чыгып, персоналның алда торучы чираттагы ялларына түләүгә резервкп исәп-хисап ясау методикасы буенча исәпләнелә.

Һәр хезмәткәр буенча алда торучы чираттагы ялларга чыгымнар суммасы түбәндәге формуладан чыгып билгеләнә.

$$\text{Чираттагы яллар резервы} = К * ЗПср,$$

биредә:

К – исәп-хисап ясау датасына (ел азагына), эшли башлаганнан бирле чор өчен хезмәткәр тарафыннан файдаланылмыйча калган чираттагы ял көннәренең гомуми күләме;

ЗПср – хезмәткәрнең бер көнлек уртача хезмәт хакы.

Чираттагы ялга кадәрге 12 айда тулысынча эшләгән очракта, бер көнлек уртача хезмәт хакы түбәндәгечә билгеләнә:

$$ЗПср = ФОТ/(12 * 29,3),$$

биредә:

ФОТ - алдагы 12 айда фактта исәпләнгән хезмәт хакы суммасы;

12 – елдагы айлар саны;

29,3 – айлык уртача календарь көннәре саны.

Чираттагы ялга кадәрге 12 айда тулысынча эшләмәгән очракта, бер көнлек уртача хезмәт хакы түбәндәгечә билгеләнә:

ЗПср = Уртача хезмәт хакын исәпләүдә исәпкә алына торган суммалар (А х 29,3 + В х 29,3/С),

биредә:

А – тулысынча эшләгән айлар саны;

В – тулысынча эшләмәгән айда (айларда) эшләгән календарь көннәре саны;

С – тулысынча эшләмәгән һәр ай (айлар) өчен айда (айларда) календарь көннәренең гомуми саны.

Иминиятләштерү взносларын түләүгә резервны исәпләү методикасы чираттагы ялга түләүгә резервны исәпләү методикасына охшатып исәпләнелә.

Резервны формалаштыруда иминиятләштерү взнослары суммасы Үзәкләштерелгән учет субъекты буенча уртача түбәндәгечә исәпләнелә

Иминиятләштерү взнослары резервы = К * ЗПср * N,
биредә:
N – иминиятләштерү взнослары тарифы.

Иминиятләшерү взнослары суммасы, иминиятләштерү взносларын исәпләү базасының чик күләмен алмыйча, иминиятләштерү взносларының максималь тарифы буенча исәпләнелә.

Чираттагы ялларның һәм иминиятләштерү взносларының гомуми резервы күләме, салымнар һәм взнослардан чыгып, барлык хезмәткәрләр буенча резервларның гомуми суммасына тигез.

Белдерелгән претензияләр һәм дәгъвалар буенча, шул исәптән суд тәртибендә бәхәсле дип игълан ителгәннәре буенча, йөкләмәләрне түләү өчен резерв рәвешендәге бәяләү йөкләмәсе һәр квартал саен бюджет учетын үзәкләштерүдә Документлар әйләнеше графигы нигезендә тапшырыла торган мәгълүматлар буенча билгеләнә (аныклана).

Претензияләр, дәгъвалар буенча йөкләмәләр һәр претензия таләбе һәм дәгъва буенча, шул исәптән претензияләрне судка кадәр (судтан тыш) карап тикшерү кысаларында, тулы күләмендә исәпкә алына.

Претензияләр, дәгъвалар буенча резерв түбәндәге претензияләр, дәгъвалар нигезендә танылa:

претензия таләбен алу датасына – Үзәкләштерелгән учет субъекты судка кадәр җайга салуны күздә тоткан, бәхәсле дип игълан ителгән претензия таләпләре буенча;

суд тикшерүенә дәгъва кабул итү турында Үзәкләштерелгән учет субъектына уведомление җибәрү датасына – Үзәкләштерелгән учет субъекты судка кадәр җайга салуны күздә тотмаган, бәхәсле дип игълан ителгән дәгъва таләпләре буенча.

Претензия таләпләре һәм дәгъвалар буенча резерв тулы күләмендә танылa: вазыйфаи затларның законсыз гамәлләре (гамәл кылмау) нәтиҗәсендә (шул исәптән Россия Федерациясе законына туры килмәүче яки башка хокукый актка туры килмәүче актлар бастырып чыгару нәтиҗәсендә) физик яки юридик затка китерелгән зыянны каплау турында претензия таләпләре һәм дәгъвалар куелганда, шулай ук көтелә торган:

суд чыгымнары – көтелә торган чыгымнарга охшаш башка претензияләр (дәгъвалар) куелган очракта. Булдырылган резервлар суммалары җитәрлек булмаганда, фактта хәл ителгән чыгымнардан артып киткән сумма агымдагы чорның чыгымнары буларак танылa.

Резервлар хакын бәяләү һәр ел саен яңадан каралырга һәм хисап датасына агымдагы нигезле бәяләүгә кадәр үзгәртелергә тиеш.

